**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Верхнестярлинскогосельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советы БАШЛЫГЫ**

ул. Советская, д32г , село Верхнее Стярле,
Азнакаевского муниципального района, 423314
Тел. (факс) (85592) 42618
VSt.Azn @tatar.ru

Совет урамы, 32г, Югары Стәрле авылы
Азнакай муниципаль районы, 423314
Тел. (факс) (85592) 42618
VSt. .Azn @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

От «05» апрель 2019 ел № 13

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 12.01.1996 ел, 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 24 гыйнварындагы 32-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. 1. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә, 2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 5 946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм №1, №2 кушымталар нигезендә гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хөкук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http//pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru.адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык Л.С.Сабиржанова

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Башкарма комитет карарына
Кушымта №1
«05» апрель 2019 № 13

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Югары Стәрле авыл җирлеге»**
**Муниципаль берәмлегендә**
**җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге**

| № | Наименование услуг | Стоимость услуг, руб. |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 50,00 |
| 2 | Табут һәм күмү өчен башка предметларны китерү | 4 018,75 |
| 3 | Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 834,57 |
| 4 | Күмү(кабер казу) | 1 043,15 |
| 5 | Барлыгы | 5 946,47 |

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Башкарма комитет карарына
Кушымта №2
«05» апрель 2019 № 13

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Югары Стәрле авыл җирлеге»**
**Муниципаль берәмлегендә**
**җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге**

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәтләр бәясе, сумнарда. |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 50 |
| 2 | Тәнне кәфенләү | 834,57 |
| 3 | Табут һәм күмү өчен башка предметларны китерү | 3 184,18 |
| 4 | Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 834,57 |
| 5 | Күмү(кабер казу) | 1 043,15 |
| | Барлыгы | 5 946,47 |